РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 29 октябре г. Буинск 85-п нче номерлы

Буа муниципаль районының тормыш дәрәҗәсен
күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча
ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Буа муниципаль районы башлыгының 2008 елның 29 августындагы 88 номерлы «Буа муниципаль районының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында» (2017 елның 18 декабрендәге 146/п номерлы, 2018 елның 25 мае 47-п номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган, Буа муниципаль районының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 15 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хокук бозу билгеләре булган хуҗалык итүче субъектларның икътисадый һәм хуҗалык эшчәнлеге фактлары буенча хокук саклау органнарына тикшерүләрне законда билгеләнгән тәртиптә башлап җибәрү максатларында мөрәҗәгать итү;»;

1.2. 4 пунктның 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тикшерүләр башкару максатларында хокук бозу билгеләре булган хуҗалык итүче субъектларның икътисадый һәм хуҗалык эшчәнлеге фактлары буенча хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт (муниципаль) контроле кысаларында тикшерүләр башлап җибәрү максатында вәкаләтле органнарга мөрәҗәгать итәргә;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Камартдинов